КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 май г.Казань № 364

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2029 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2029 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 октябрь, 828 нче; 2012 ел, 7 февраль, 89 нчы; 2012 ел, 10 ноябрь, 977 нче; 2013 ел, 19 март, 191 нче; 2013 ел, 30 май, 361 нче; 2014 ел, 8 июль, 465 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 846 нчы; 2019 ел, 1 февраль, 61 нче; 2019 ел, 28 август, 721 нче; 2023 ел, 7 август, 950 нче; 2023 ел, 30 декабрь, 1768 нче, 2024 ел, 27 гыйнвар, 37 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), әлеге карарга теркәлгән кушымтаның 6 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| «6. Яшьләр сәясәте оешмалары | | |
|---|---|---|
| 6.1. Яшьләр үзәкләре (оешмалар төрләре нигезендә структур бүлекчәләр белән) | оешмалар | 1 - муниципаль берәмлеккә;<br>6 дәүләтнеке - Татарстан Республикасы өчен |
| 6.2. Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары (оешмалар төрләре нигезендә структур бүлекчәләр белән) | оешмалар | 1 - 50 меңнән артык халкы булган муниципаль берәмлеккә; |

| | | |
|---|---|---|
| 6.3. Балалар һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәкләре (структур бүлекчәсе белән балалар һәм яшьләр өчен телефон аша экстрен психологик ярдәм үзәге) | оешмалар | 1 - 50 меңнән артык халкы булган муниципаль берәмлеккә; |
| 6.4. Иҗтимагый тәртипне саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәкләре | оешмалар | 1 - 100 меңнән артык халкы булган муниципаль берәмлеккә;<br>1 дәүләтнеке - Татарстан Республикасы өчен |
| 6.5. Студентлар хезмәт отрядлары үзәкләре | оешмалар | 1 - 100 меңнән артык халкы булган муниципаль берәмлеккә;<br>1 дәүләтнеке - Татарстан Республикасы өчен |
| 6.6. Балалар һәм яшүсмерләр ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру үзәкләре | оешмалар | 1 - 500 меңнән артык халкы булган муниципаль берәмлеккә;<br>2 дәүләтнеке - Татарстан Республикасы өчен |
| 6.7. Сәламәтләндерү-ял итү учреждениеләре (лагерьлар) | оешмалар | муниципаль районнар, шәһәр округлары өчен - 2023 елның 1 гыйнварына торышына фактта тәэмин ителеш дәрәҗәсендә |
| 6.8. Хәрби-патриотик эшләр һәм хәрби хезмәткә чакырганга кадәр әзерләү үзәкләре | оешмалар | 1 - 100 меңнән артык халкы булган муниципаль берәмлеккә;<br>1 дәүләтнеке - Татарстан Республикасы өчен |
| 6.9. Республика яшьләр, инновация һәм профилактика программалары үзәге | оешмалар | 1 дәүләтнеке - Татарстан Республикасы өчен |
| 6.10. «Иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү республика үзәге | оешмалар | 1 дәүләтнеке - Татарстан Республикасы өчен». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин